КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 26 октябрь г.Казань № 1144

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында махсус саклана торган табигать территорияләре дәүләт реестрын раслау һәм махсус саклана торган табигать территорияләре мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында» 2009 ел, 24 июль, 520 нче карары белән расланган Татарстан Республикасында махсус саклана торган табигать территорияләре дәүләт реестрына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында махсус саклана торган табигать территорияләре дәүләт реестрын раслау һәм махсус саклана торган табигать территорияләре мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында» 2009 ел, 24 июль, 520 нче карары белән (Татарстан Республикасы Мини-стрлар Кабинетының 2010 ел, 24 март, 192 нче; 2011 ел, 13 май, 393 нче; 2011 ел, 26 июль, 604 нче; 2011 ел, 8 август, 641 нче; 2012 ел, 17 июль, 600 нче; 2013 ел, 27 март, 208 нче; 2013 ел, 1 июнь, 374 нче; 2013 ел, 6 июнь, 390 нчы; 2014 ел, 20 май, 335 нче; 2014 ел, 11 июнь, 399 нчы; 2014 ел, 17 октябрь, 767 нче; 2014 ел, 24 ноябрь, 904 нче; 2016 ел, 11 июль, 475 нче; 2016 ел, 21 июль, 493 нче; 2017 ел, 31 гыйнвар, 42 нче; 2017 ел, 30 сентябрь, 744 нче; 2018 ел, 12 февраль, 76 нчы; 2018 ел, 21 май, 380 нче; 2019 ел, 26 март, 221 нче; 2019 ел, 28 май, 445 нче; 2020 ел, 5 февраль, 77 нче; 2020 ел, 6 октябрь, 909 нчы; 2020 ел, 4 ноябрь, 994 нче; 2022 ел, 28 февраль, 183 нче; 2022 ел, 16 июнь, 569 нчы; 2022 ел, 18 август, 853 нче,


2022 ел, 02 сентябрь, 953 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасында махсус саклана торган табигать территорияләре дәүләт реестрына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

«Әгерҗе муниципаль районы» бүлегендә:

«Кама-Ык [207]» бүлекчәсен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Кама-Ык [207]

| | |
|---|---|
| Статус | Комплекслы профильле төбәк әһәмиятендәге дәүләт табигать тыюлыгы |
| Гамәлгә кую документлары | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 ел, 28 август, 751 нче карары |
| Урнашу урыны | Татарстан Республикасы Әгерҗе, Актаныш, Минзәлә һәм Тукай муниципаль районнары |
| Башкарма хакимиятнең контрольдә тотучы дәүләт органы | Татарстан Республикасының Биологик ресурслар буенча дәүләт комитеты |



Объектның тасвирнамәсе һәм аның әһәмияте. Тыюлыкның гомуми мәйданы 22 291,48 гектар тәшкил итә.

Тыюлыкны оештыру Татарстан Республикасының Кызыл китабына кертелгән табигый комплексларны саклау, үсемлекләрнең һәм хайваннарның су һәм су тирәли төрләрен саклау зарурлыгына нигезләнгән.

Тыюлык территориясе картайган күлләрне, сазлык массивларын, кара зирекле урманнарны, тотылган имәнлекләрне һәм тотылган болыннарны үз эченә алган су-сазлык җирләреннән тора.


Әлеге территория бер төркем үсемлек һәм хайванның, шул исәптән Татарстан Республикасының Кызыл китабына кертелгән төрләренең (үсемлекләр: ак төнбоек, сары кубышка, сазлык кырлы борчагы, сазлык дремлигы, ике яфраклы любка; хайваннар: ысылдавык аккош, зимородок, соры торна,  ак койрыклы бөркет, сазлык ташбакасы) яшәү урыны булып тора.

Саклау чаралары. Россия Федерациясе законнарында  һәм Татарстан Республикасы законнарында билгеләнгән тыюлыкны саклау режимы нигезендә.»;

«Актаныш муниципаль районы» бүлегендә:

Актаныш муниципаль районының карта-схемасын һәм аңа бирелгән искәрмәләрне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Актаныш муниципаль районы





[4] – Река Ик
[13] – Река Сюнь
[14] – Озеро Копаное
[207] – Камско-Иксдкий
[208] – Дельта реки Белой»;

«Копаное күле [14]» бүлекчәсен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Копаное күле [14]

| | |
|---|---|
| Статус | Төбәк әһәмиятендәге табигать һәйкәле |
| Гамәлгә кую документлары | Татарстан АССР Министрлар Советының 1978 елның 10 гыйнварындагы 25 номерлы карары<br>Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2005 ел, 29 декабрь, 644 нче карары |
| Урнашу урыны | Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы |
| Башкарма хакимиятнең контрольдә тотучы дәүләт органы | Татарстан Республикасының Биологик ресурслар буенча дәүләт комитеты |




Объектның тасвирнамәсе һәм аның әһәмияте. Табигать һәйкәленең гомуми мәйданы 0,86 гектар тәшкил итә.

Турыпочмаклы формадагы, ясалма су бүлү күле. Өстән туклану. Урта минерализация суы, уртача катылыкта. Гидробонат-кальций суның химик тибы.


Су тирәлегендә суалчаннарның 9 төре, 3 - тармаклы мыеклылар һәм 6 - кысласыманнар тереклек итә.

Саклау чаралары. Россия Федерациясе законнарында һәм Татарстан Республикасы законнарында билгеләнгән табигать һәйкәлен саклау режимы нигезендә.»;

«Әлмәт муниципаль районы» бүлегендә:

Әлмәт муниципаль районының карта-схемасын һәм аңа бирелгән искәрмәләрне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:


«Әлмәт муниципаль районы




«Акташ упкыны күле [22]» бүлекчәсен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Акташ упкыны күле [22]

| | |
|---|---|
| Статус | Төбәк әһәмиятендәге табигать һәйкәле |
| Гамәлгә кую документлары | Татарстан АССР Министрлар Советының 1978 елның 10 гыйнварындагы 25 номерлы карары<br>Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2005 ел, 29 декабрь, 644 нче карары |
| Урнашу урыны | Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы |
| Башкарма хакимиятнең контрольдә тотучы дәүләт органы | Татарстан Республикасының Биологик ресурслар буенча дәүләт комитеты |




Объектның тасвирнамәсе һәм аның әһәмияте. Табигать һәйкәленең гомуми мәйданы 0,05 гектар тәшкил итә.

Су бүлү күле түгәрәк формасында, килеп чыгышы карстлы. Упкын 1939 елда барлыкка килгән, беренчел зурлыгы якынча 3 × 2 метр булган. Төрле мәгълүматлар буенча, упкынның тирәнлеге 50 дән 80 метрга кадәр тәшкил иткән. 1951 елда, Г.Н.Петров мәгълүматлары буенча, бүрәнкәнең диаметры якынча 50 метр һәм тирәнлеге 25 метр чамасы булган. Упкын төбендә диаметры 10 метр чамасы булган күл барлыкка килгән, ул көнбатыш сөзәклек итәгендә башланган чишмә хисабына туена. 15 елдан соң упкын тирәнлеге (суга кадәр) 20 метрга кадәр диярлек кимегән.


Җир асты туклануы, тотрыклы. Югары минерализацияле су, каты. Гидробонат-кальций суның химик тибы.

Саклау чаралары. Россия Федерациясе законнарында һәм Татарстан Республикасы законнарында билгеләнгән табигать һәйкәлен саклау режимы нигезендә.»;

«Балтач муниципаль районы» бүлегендә:

Балтач муниципаль районының карта-схемасын һәм аңа бирелгән искәрмәләрне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Балтач муниципаль районы





[29] – Река Шошма
[30] – Рукотворный лес
[39] – Озеро Каракуль
[35] – Сурнарский
[173] – Балтасинский
[212] – Ципьинский лес»;

«Каракүл күле [39]» бүлекчәсен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Каракүл күле [39]

| | |
|---|---|
| Статус | Төбәк әһәмиятендәге табигать һәйкәле |
| Гамәлгә кую документлары | Татарстан АССР Министрлар Советының 1978 елның 10 гыйнварындагы 25 номерлы карары<br>Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2005 ел, 29 декабрь, 644 нче карары |
| Урнашу урыны | Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы |
| Башкарма хакимиятнең контрольдә тотучы дәүләт органы | Татарстан Республикасының Биологик ресурслар буенча дәүләт комитеты |




Объектның тасвирнамәсе һәм аның әһәмияте. Табигать һәйкәленең гомуми мәйданы 2,5 гектар тәшкил итә.

Озынча формадагы су үзәне, карстлы чгышлы, зурлыгы буенча зур булмаган, ләкин тирән кратерсыман (18 метрга кадәр максималь тирәнлек) күл. Бик матур ярлары булган күл ылыслы урман белән әйләндереп алынган, ихтиофаунага бай.


Җир асты туклануы, тотрыклы. Суы урта минерализацияле, уртача катылыкта, аз опалесцирияле. Суның химик тибы гидробонат-сульфат-кальцийлы.

Саклау чаралары. Россия Федерациясе законнарында һәм Татарстан Республикасы законнарында билгеләнгән табигать һәйкәлен саклау режимы нигезендә.»;

«Буа муниципаль районы» бүлегендә:

Буа муниципаль районының карта-схемасын һәм аңа бирелгән искәрмәләрне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Буа муниципаль районы





[25] – Река Свияга
[26] – Река Улема
[48] – Ново-Тинчалинская сурковая колония
[49] – Утинская сурковая колония
[50] – Парк имени декабриста В.П.Ивашева
[182] – Зея буйлары»;

«Үтинкә сөркә (байбак) колониясе [49]» бүлекчәсен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Үтинкә сөркә (байбак) колониясе [49]

| | |
|---|---|
| Статус | Төбәк әһәмиятендәге табигать һәйкәле |
| Гамәлгә кую документлары | Татарстан АССР Министрлар Советының 1987 елның 21 декабрендәге 486 номерлы карары<br>Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2005 ел, 29 декабрь, 644 нче карары |
| Урнашу урыны | Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы |
| Башкарма хакимиятнең контрольдә тотучы дәүләт органы | Татарстан Республикасының Биологик ресурслар буенча дәүләт комитеты |




Объектның тасвирнамәсе һәм аның әһәмияте. Табигать һәйкәленең гомуми мәйданы 50 гектар тәшкил итә.

Табигать һәйкәлен оештыру сөркә (байбак) колониясен саклау зарурлыгына нигезләнгән.

Территория чокыр төбеннән инеш ага торган чокыр-ерганак системасыннан гыйбарәт. Анда 1991 елда буа белән бүленгән Карлы елгасының сул кушылдыгы урнашкан. Туфрак - кара җир.

Территория флорасында үлән үсемлекләрнең 70 тән артык төре бар. Әлеге территория үсемлек һәм хайваннарның бик күп төрләре, шул исәптән Татарстан Республикасының Кызыл китабына кертелгән төрләре (үсемлекләр: язгы утчәчәк, астрагаллар; хайваннар: саз карчыгасы, һөдһөд, ысылдавык аккош, тимгелле йомран, сукыр тычкан) яшәү урыны булып тора.

Табигать һәйкәле территориясендә Европа байбагы колониясе яши.

Саклау чаралары. Россия Федерациясе законнарында һәм Татарстан Республикасы законнарында билгеләнгән табигать һәйкәлен саклау режимы нигезендә.»;

“Декабрист В.Г.Ивашев биләмәсе паркы [50]” бүлекчәсенең исемен түбәндәге


редакциядә бәян итәргә:

«Декабрист В.П.Ивашев исемендәге парк [50]»;

«Чүпрәле муниципаль районы» бүлегендә:

Чүпрәле муниципаль районының карта-схемасын һәм аңа бирелгән искәрмәләрне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Чүпрәле муниципаль районы





[68] – Кереметь (Ново-Чекурская лесостепь)
[177] – Биби-Айша
[178] – Исток реки Цильны
[179] – Чистая поляна
[180] – Овраг Шерелдаук
[181] – Мордовские луга»;

«Биби-Әйшә [177]» бүлекчәсен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Биби-Әйшә [177]

| | |
|---|---|
| Статус | Төбәк әһәмиятендәге табигать һәйкәле |
| Гамәлгә кую документлары | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2008 ел, 5 март, 141 нче карары |
| Урнашу урыны | Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы |
| Башкарма хакимиятнең контрольдә тотучы дәүләт органы | Татарстан Республикасының Биологик ресурслар буенча дәүләт комитеты |




Объектның тасвирнамәсе һәм аның әһәмияте. Табигать һәйкәленең гомуми мәйданы 73,5 гектар тәшкил итә.

Табигать һәйкәлен оештыру уникаль ландшафт комплексларын саклау һәм Чүпрәле муниципаль районында экологик хәлне нормальләштерү зарурлыгына нигезләнгән.

Табигать һәйкәле ике чокыр-балка системасы буйлап тар полоса белән сузылган коры җир болынынннан гыйбарәт. Чокыр-балка системаларының берсе урыны белән тирән итеп ярылган һәм аның төбе буйлап Зур Цильна елгасына коя торган инеш ага. Мәйданы буенча зур булмаган сазлыклы участоклары бар.

Үсемлекләр төрле вариантларда - көтүлекле кыяклы, кыяклы үләнле һәм кыяклы-рудераль болыннарда. Чокырлар һәм балкалар төпләрендә түбән сазлыклар җәелгән, аларда урман камышы һәм киң яфраклы камыш өстенлек ала, киң яфарклы сазлык үләне бар.

Табигать һәйкәле флорасында 70 төргә һәм 27 гаиләгә караган югары күп тамырлы үсемлекләрнең 80 төре билгеләп үтелде. Әлеге территория бер төркем хайваннарның, шул исәптән Татарстан Республикасының Кызыл китабына кертелгән хайваннарның (алтын чуртан, болын карчыгасы, тимгелле йомран) яшәү урыны булып тора.


Саклау чаралары. Россия Федерациясе законнарында һәм Татарстан

Республикасы законнарында билгеләнгән табигать һәйкәлен саклау режимы нигезендә.»;

«Чиста алан [179]» бүлекчәсен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Чиста алан [179]

| | |
|---|---|
| Статус | Төбәк әһәмиятендәге табигать һәйкәле |
| Гамәлгә кую документлары | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2008 ел, 5 март, 141 нче карары |
| Урнашу урыны | Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы |
| Башкарма хакимиятнең контрольдә тотучы дәүләт органы | Татарстан Республикасының Биологик ресурслар буенча дәүләт комитеты |




Объектның тасвирнамәсе һәм аның әһәмияте. Табигать һәйкәленең гомуми мәйданы 269,7 гектар тәшкил итә.

Табигать һәйкәлен оештыру уникаль ландшафт комплексларын саклау һәм Чүпрәле муниципаль районында экологик хәлне нормальләштерү зарурлыгына нигезләнгән.

Табигать һәйкәле чокыр-балкалы система булып тора, аның төбе буенча елга ага, ул Бездна елгасына коя. Шулай ук урманга терәлеп торган берничә «асылма» саз бар, шуларның берсе - сфагновлы.

Территориянең күпчелек өлеше үсемлекләре төрле типтагы печәнлекләрдән һәм көтүлекләрдән гыйбарәт.


Табигать һәйкәле флорасында 49 төргә һәм 23 гаиләгә караган югары күп тамырлы үсемлекләрнең 72 төре билгеләп үтелде. Әлеге территория бер төркем хайваннарның, шул исәптән Татарстан Республикасының Кызыл китабына кертелгән хайваннарның (гади кара елан, алтын чуртан, болын карчыгасы) яшәү урыны булып тора.

Саклау чаралары. Россия Федерациясе законнарында һәм Татарстан Республикасы законнарында билгеләнгән табигать һәйкәлен саклау режимы нигезендә.»;

«Мордва болыннары [181]» бүлекчәсен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Мордва болыннары [181]

| | |
|---|---|
| Статус | Төбәк әһәмиятендәге табигать һәйкәле |
| Гамәлгә кую документлары | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2008 ел, 5 март, 141 нче карары |
| Урнашу урыны | Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы |
| Башкарма хакимиятнең контрольдә тотучы дәүләт органы | Татарстан Республикасының Биологик ресурслар буенча дәүләт комитеты |




Объектның тасвирнамәсе һәм аның әһәмияте. Табигать һәйкәленең гомуми мәйданы 34,1 гектар тәшкил итә.

Табигать һәйкәлен оештыру уникаль ландшафт комплексларын саклау һәм Чүпрәле муниципаль районында экологик хәлне нормальләштерү зарурлыгына нигезләнгән.

Табигать һәйкәле чокыр-балкалы система булып тора, аның төбе буенча инеш ага, ул Зур Якла елгасына коя. Шулай ук агач-куак үсемлекләренең аерым чәчәклекләре дә бар. Зур булмаган мәйданнарда, түбәнлектә, болыннарның сазлыкка әйләнүе башлана. Балкалар битләрендә «асылма» сазлыклар очрый. Туфрак катламын шушы сазлыкка таба юып төшерү урыны бар. Шулай итеп, әлеге территория ландшафтның күптөрле элементларын үз эченә ала, бу монда төрле экологик төркемнәргә керүче хайваннар яшәвен тәэмин итә.

Үсемлекләр төрле вариантларда - көтүлекле кыяклы, кыяклы үләнле һәм кыяклы-рудераль болыннарда.

Тикшерелгән участок флорасында 62 төргә һәм 27 гаиләгә караган югары күп тамырлы үсемлекләрнең 77 төре билгеләп үтелде. Әлеге территория бер төркем хайваннарның, шул исәптән Татарстан Республикасының Кызыл китабына кертелгән


хайваннарның (алтын чуртан, болын карчыгасы) яшәү урыны булып тора.

Саклау чаралары. Россия Федерациясе законнарында һәм Татарстан Республикасы законнарында билгеләнгән табигать һәйкәлен саклау режимы нигезендә.»;

«Кайбыч муниципаль районы» бүлегендә:

Кайбыч муниципаль районының карта-схемасын һәм аңа бирелгән искәрмәләрне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Кайбыч муниципаль районы





[25] – Река Свияга
[87] – Река Бирля
[88] – Озеро Большое
[89] – Кайбицкие дубравы
[90] – Турминская дача
[183] – Поймы рек Свияги и Кубни
[184] – Озерный комплекс у поселка Новое Патрикеево»;

«Зур күл [88]» бүлекчәсен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Зур күл [88]

| | |
|---|---|
| Статус | Төбәк әһәмиятендәге табигать һәйкәле |
| Гамәлгә кую документлары | Татарстан АССР Министрлар Советының 1978 елның 10 гыйнварындагы 25 номерлы карары<br>Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2005 ел, 29 декабрь, 644 нче карары |
| Урнашу урыны | Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль |

| | |
|---|---|
| | районы |
| Башкарма хакимиятнең контрольдә тотучы дәүләт органы | Татарстан Республикасының Биологик ресурслар буенча дәүләт комитеты |




Объектның тасвирнамәсе һәм аның әһәмияте. Табигать һәйкәленең гомуми мәйданы 1,8 гектар тәшкил итә.

Су бүлү күле түгәрәк формасында, килеп чыгышы карстлы. Җир асты туклануы, тотрыклы. Суы йомшак минерализацияле, бик йомшак. Гидробонат-кальций суның химик тибы.

Су фаунасының вәкиллеге аз санлы: планктонды кысласыманнарның 3 төре һәм бентоста яшәүчеләрнең 4 төре.

Саклау чаралары. Россия Федерациясе законнарында һәм Татарстан Республикасы законнарында билгеләнгән табигать һәйкәлен саклау режимы нигезендә.»;


«Яңа Патрикеево бистәсе янында күл комплексы [184] бүлекчәсенең исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Яңа Патрикеево бистәсе янында күл комплексы [184]»;

«Лаеш муниципаль районы» бүлегендә:

Лаеш муниципаль районының карта-схемасын һәм аңа бирелгән искәрмәләрне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Лаеш муниципаль районы




[76б] – Волжско-Камский государственный природный биосферный заповедник (Саралинский участок)
[76г] – Охранная зона Саралинского участка Волжско-Камского государственного природного биосферного заповедника
[101] – Река Меша
[106] – Озеро Архиерейское
[107] – Озеро Ковалинское
[108] – Озеро Заячье
[109] – Озеро Моховое
[110] – Озеро Лесное
[111] – Озеро Саламыковское
[112] – Озеро Сапуголи
[113] – Озеро Свежье
[114] – Озеро Столбище
[115] – Озеро Чистое
[116] – Озеро Черное
[117] – Озеро Черное
[118] – Гнездовая колония серой чайки
[200] – Нерестилище стерляди
[201] – Устье реки Меши
[206] – Волжские просторы»;

«Идел-Кама дәүләт табигый биосфера тыюлыгындагы Саратов участогының саклау зонасы» бүлекчәсе исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Идел-Кама дәүләт табигый биосфера тыюлыгындагы Саратов участогының саклау зонасы [76г]».


«Свежее күле [113]» бүлекчәсе исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Свежее күле [113]»;

«Кара күл [117]» бүлекчәсен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Кара күл [117]

| | |
|---|---|
| Статус | Төбәк әһәмиятендәге табигать һәйкәле |
| Гамәлгә кую документлары | Татарстан АССР Министрлар Советының 1978 елның 10 гыйнварындагы 25 номерлы карары<br>Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2005 ел, 29 декабрь, 644 нче карары |
| Урнашу урыны | Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы |
| Башкарма хакимиятнең контрольдә тотучы дәүләт органы | Татарстан Республикасының Биологик ресурслар буенча дәүләт комитеты |




Объектның тасвирнамәсе һәм аның әһәмияте. Табигать һәйкәленең гомуми мәйданы 4,4 гектар тәшкил итә.

Су бүлү күле озынча формасында, килеп чыгышы карстлы. Җир асты

туклануы, тотрыклы. Суы йомшак минерализацияле, бик йомшак. Гидробонат-кальций суның химик тибы.

Су тирәлегендә суалчаннарның 5 төре, 11 - планктон кысласыманнар, 8 - суүсемнәр, 3 - инфузорий, бентосның 9 таксономик төркеме тереклек итә.

Саклау чаралары. Россия Федерациясе законнарында һәм Татарстан Республикасы законнарында билгеләнгән табигать һәйкәлен саклау режимы нигезендә.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин